ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6 статья. **Дәүләт хезмәте вазыйфалары**

1. Дәүләт хезмәте вазыйфалары – Татарстан Республикасы дәүләт органының йә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү максатларында, Федераль закон, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә куела торган вазыйфалар.

2. Дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфалар да каралырга мөмкин. Мондый вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрнең хезмәт эшчәнлеге хезмәт турында Россия Федерациясе законнары белән җайга салына.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2014 елның 15 декабре
№ 120-ТРЗ